СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**6 февраль 2023 ел** Болгар ш. **№ 26-2**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» һәм «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чикләрен үзгәртү инициативасын тәкъдим итү турында


«Россия Федерацияләрендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, ТР Спас муниципаль районы Уставы нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләренә кергән җир кишәрлеген Приволжский авыл җирлегенә кертү юлы белән «Болгар шәһәре» һәм «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чикләрен үзгәртү инициативасын тәкъдим итәргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына тәкъдим ителгән чикләрне үзгәртү буенча фикер белдерергә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны «Яңа тормыш» («Новая жизнь») район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Спас муниципаль районы башлыгы урынбасары С.И. Тюнев

«Болгар шәһәре» һәм «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең чиктәш чикләре Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Приволжский авыл җирлегенә «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге чигенә керә торган Приволжский бистәсе өлешендәге җир кишәрлеген кертү юлы белән үзгәрешләр.




Шартлы билгеләр: **гамәлдәге чикләр.**

**үзгәрүдән соң чикләр.**